| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2021 Казан ш. № 639-117/тэ-2021

«РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 №5-115/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2022 елга җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2020-2022 елларга тарифлар билгеләү хакында» 13.12.2019 № 5-115/тэ карарының 1 нче кушымтасына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2020 №415-75/тэ-2020 карары керткән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-115/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 № 639-117/тэ-2021 карары редакциясендә)

## «РСК» ҖЧҖ тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2020-2022 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясе чыганагы төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | Пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «РСК» ҖЧҖ, Казан шәһәренең ЕТО-2* эш итү зонасында | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 627,02 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 650,24 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 556,92 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 566,79 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 559,42 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 609,34 | - |

<*> - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2018 елның 16 августындагы 658 номерлы боерыгы белән расланган Казан шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге